СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.09.2023 г.Зеленодольск № 130

Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибен раслау турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы көрәш турында» 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре» 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибен расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибе» 2017 елның 20 сентябрендәге 141 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Мэры,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск шәһәре Советының
2023 елның 26 сентябрендәге
130 номерлы карарына
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның һәм аларның гаилә әгъзаларының тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфа биләүче затларга (җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына, муниципаль вазыйфаны биләүче башка затка) кагыла.

2. Әлеге Тәртип «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (алга таба - рәсми сайт), әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи затларның (алга таба - вазыйфаи затлар), аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне(алга таба-белешмәләр) урнаштыру процедурасын , шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыруның һәм (яки) аларны массакүләм мәгълүмат чараларына бирүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, массакүләм мәгълүмат чараларына, аларның мөрәҗәгатьләренә бәйле рәвештә, бастырып чыгару өчен белешмәләр бирүне регламентлаштыра.

3. Рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен түбәндәге белешмәләр бирелә:

а) вазифаи затка, аның хатынына (тормыш иптәшенә) һәм балигъ булмаган балаларга милек хокукына караган яки аларның файдалануында булган күчемсез милек объектлары исемлеге, мондый объектларның һәрберсенең төрен, мәйданын һәм урнашу илен күрсәтеп;

б) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр ((оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) , цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча килешүләр башкарылган (килешү башкарылган) акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр

мондый килешүләрнең гомуми суммасы (шундый килешү суммасы) вазифаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елда гомуми керемнән артып китсә.

4. Рәсми сайтта урнаштырылган һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирелгән белешмәләрдә түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а)вазифаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, әлеге затларның милек хокукында булган мөлкәте һәм аларның мөлкәт характерындагы йөкләмәләре турында башка белешмәләрне (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгәннән тыш) ;

б) ире (хатыны), балалары һәм вазыйфаи зат гаиләсенең башка әгъзаларының персональ мәгълүматлары;

в) вазифаи затның, аның хатынының (иренең), балаларының һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм башка шәхси коммуникация чараларын билгеләргә мөмкинлек бирүче мәгълүматларны;

г) вазыйфаи затка, аның хатынына (иренә), балаларына, гаиләнең башка әгъзаларына караган яисә файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматларны;

д) дәүләт серенә кертелгән яки конфиденциаль булган мәгълүматны.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр, аларны бирү өчен билгеләнгән срок узганнан соң, 14 эш көне эчендә рәсми сайтка урнаштырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтка урнаштыру Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге (алга таба - кадрлар хезмәте) белән тәэмин ителә.

7. Рәсми сайтта урнаштырылган белешмәләр, шул исәптән вазифаи затның алдагы еллары өчен дә, үз вазыйфасын биләгән чор дәвамында, ачык кулланылышта (рәсми сайтларда урнаштырылган) була.

8. Вазыйфаи зат тарафыннан төгәлләнгән белешмәләр тапшырылганда, тиешле үзгәрешләр рәсми сайтта урнаштырылган белешмәләргә, төгәлләнгән белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң, 14 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

9. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан рәсми мөрәҗәгать кергәндә кадрлар хезмәте:

а) рәсми мөрәҗәгать кергән көннән алып өч эш көне эчендә, кергән кешегә карата булган рәсми мөрәҗәгать турында вазыйфаи затка хәбәр итә;

б) рәсми мөрәҗәгать кергән көннән алып җиде эш көне эчендә, әгәр соралган белешмәләр рәсми сайтта булмаса, әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне тәэмин итә.

10. Кадрлар хезмәтенең муниципаль хезмәткәрләре әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне фаш иткән өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы.